**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР  
от 22.07.2024

ПОСТАНОВЛЕНИЕ  
№ ПР-134

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2024-2025 уку елына балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән мәктәп автобус маршрутларын ачу турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларыннан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 03 августындагы 400 нче номерлы карарын үтәү йөзеннән, балаларны йөртү өчен кулланыла торган автобуслар белән укучыларны йөртүнең иминлеген тәэмин итү максатларында**,** Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2024 елның 28 июнендәге мәктәп автобусларының хәрәкәт итү маршрутларын тикшерү акты нигезендә, 2024 елның 1 сентябреннән түбәндәге автобус маршрутларын ачарга:

1. «Татар-Суыксу төп гомуми белем бирү мәктәбе»1 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
2. «Актаныш 1 санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе»2 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
3. «2 санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» 2 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
4. «2 санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе»2 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
5. «2 санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» 2 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
6. «Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» 3 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
7. «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» 4 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
8. «1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» 5 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты; (2 нче автобус)
9. «Югары Яхшый төп гомуми белем бирү мәктәбе» 6 нчы эчке муниципаль махсус мәктәп мәктәп маршруты;
10. «Киров урта гомуми белем бирү мәктәбе» 7 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
11. «Әтәс төп гомуми белем бирү мәктәбе» 8 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты
12. «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» 9 нчы эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;
13. «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» 9 нчы эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;

14. «Богады төп гомуми белем бирү мәктәбе» 10 нчы эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;

15. «Сәфәр урта гомуми белем бирү мәктәбе» 11 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;

16. «Теләкәй төп гомуми белем бирү мәктәбе» 12 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;

17. «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» 13 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;

18. «Аккүз төп гомуми белем бирү мәктәбе» - «Меңнәр төп гомуми белем бирү мәктәбе» 14 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;

19. «Яңа Әлем төп гомуми белем бирү мәктәбе» 15 нче эчке муниципаль махсус мәктәп маршруты;

2. «Татавтодор» АҖ Минзәлә филиалының Актаныш ДРСУ башлыгына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә автомобиль юлларын, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны даими чистартуны оештырырга.

3. Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә автомобиль юлларын, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны даими чистартуны оештырырга.

4. «Актаныш АТХ» МУП директорына тәкъдим итәргә:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ белән килештерелгән автобус маршрутлары паспортларын һәм автобуслар хәрәкәте расписаниесен эшләргә һәм раслауга тапшырырга;

- мәктәп маршрутларын тикшерүнең рәсмиләштерелгән актларын тикшерү тәмамланганнан соң биш көн эчендә Башкарма комитет җитәкчесенә тапшырырга;

- расланган расписание нигезендә мәктәп автобусларын эксплуатацияләүне катгый тәэмин итү;

- инструктаж мәҗбүри үткәрелеп, кимендә 3 ел эш стажы булган машина йөртүчеләрне сайлап алуны тәэмин итәргә;

- мәктәп автобусларын эксплуатацияләү өчен җаваплы башкаручыларны билгеләү буенча боерык чыгарырга.

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча ЮХИДИ бүлеге башлыгына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры китереп, күрсәтелгән маршрутлар буенча мәктәп автобусларының куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча катгый контроль оештырырга.

6. Гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына:

- балаларны торак пунктлардан база мәктәбенә кадәр алып бару һәм кире кайтару өчен, балаларның исемлеген күрсәтеп, җаваплы укытучыларны (озатып йөрүче) билгеләргә. Ай саен озатып йөрүче укытучылар һәм укучылар белән мәҗбүри инструктажлар үткәрергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

8. Башкарма комитет җитәкчесенең 2023 елның 26 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән мәктәп автобус маршрутларын ачу турында» ПР-116 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.М. Анваровага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.А. Ильясов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00C2FDA01BF7AD4C16523A87B9D8F81326
Владелец: Ильясов Рустем Алмазович
Действителен с 10.06.2024 до 03.09.2025



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН